# ГАЛӘМ

*декабрь*

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ЮЛСУБИНО ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ» ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

***№4***




9 нчы декабрьдә Ватан Геройлары көне билгеләп үтелде. Бу көнне Юнармия членнары Ватан тарихы буенча тест эшләде, мәктәптә Хәтер вахтасы оештырылды. Сыйныфларда Ватанны саклауда батырлык күрсәткән Геройлар турында хатирәләр яңартылды.

Бу атнада сыйныф сәгатьләре, “Коррупциягә – юк!” дигән девиз астында, коррупциягә каршы көрәшкә багышланды.


Безнең мәктәп укучылары төрле конкурсларда, конференцияләрдә, олимпиадаларда актив катнаша һәм еш кына җиңү яулый.

8 нче декабрь көнне кулланучылар хокукларын яклау буенча республика олимпиадасының махсус номинациясендә призер булган 9 нчы сыйныф укучысы Кәримуллина Гөлзидә грамота һәм смартфон белән бүләкләнде.

Укучыларыбызга алга таба да уңышлар телибез!



.



5 нче сыйныф укучылары безне гаҗәпләндерүләрен дәвам итәләр. Дәрестән соң аларның кабинеты бик җыйнаксыз кала, дежурныйлар да вазифаларын тиешенчә үтәми. Костюм-чалбарлар нишләптер урындык аркасында, парта өстендә кәгазь чүпләре, идәндә аяк киемнәре аунап ята, урындыкта ашалып бетмәгән печеньелар, ә гардеробта үзен килеп алганны көтеп ятучы тарих дәреслеге... Кайчан үзгәрәсез инде сез 5 ләр?!

| | |
|---|---|
|  | 1993 ЕЛНЫҢ 12 ДЕКАБРЕНДӘ КАБУЛ ИТЕЛГӘН ТӨП ЗАКОН КЕШЕНЕ, АНЫҢ ГРАЖДАНЛЫК ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ ДЕМОКРАТИК ИРЕКЛӘРЕН ИҢ ЗУР ХӘЗИНӘ ДИП ИГЪЛАН ИТТЕ. КОНСТИТУЦИЯ РОССИЯНЕҢ, СОЦИАЛЬ ДӘҮЛӘТ БУЛАРАК, ФЕДЕРАТИВ КОРЫЛЫШЫ НИГЕЗЛӘРЕН ЗАКОННАР БЕЛӘН НЫГЫТТЫ, АНЫҢ ПРОГРЕССИВ ҮСЕШЕНЕҢ ХОКУКЫЙ НИГЕЗЕН БУЛДЫРДЫ, ҖӘМГЫЯТЬ ҮСЕШЕНЕҢ ЯҢА СӘХИФӘСЕН АЧТЫ, ГРАЖДАННАР АРАСЫНДА ТАТУЛЫКНЫ ҺӘМ ҮЗАРА АҢЛАШУНЫ САКЛАП КАЛУ ӨЧЕН НЫКЛЫ ТЕРӘК БУЛДЫ. УЗГАН ЕЛЛАР ДӘВАМЫНДА ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕНЕҢ КАКШАМАС ДЕМОКРАТИЯ НИГЕЗЛӘРЕН ГАРАНТИЯЛИ ТОРГАН ТОТРЫКЛЫ КОНСТИТУЦИЯ СИСТЕМАСЫ БАРЛЫККА КИЛДЕ. |
|  | **СӘЛАМӘТ ТӘНДӘ - СӘЛАМӘТ АКЫЛ**<br><br>МӘКТӘБЕБЕЗДӘ ҺӘР ЧӘРШӘМБЕ СӘЛАМӘТЛЕК ДӘРЕСЛӘРЕ УЗА. АНЫ ДЕЖУР СЫЙНЫФЛАР УЗДЫРА. УКУЧЫЛАР БИК ТЕЛӘП ТӨРЛЕ ФИЗИК КУНЕГҮЛӘРНЕ БАШКАРАЛАР. ФИЗКУЛЬТУРАНЫ ЯРАТУ БАШКА ФӘННӘРНЕ ДӘ ҮЗЛӘШТЕРЕРГӘ ЯРДӘМ ИТӘ. |
|  | **ЯҢА ЕЛ БЕЛӘН!**<br><br>ЯҢА ЕЛГА САНАУЛЫ КӨННӘР ГЕНӘ КАЛЫП БАРА. СЫЙНЫФЛАРНЫ ДА БИЗИСЕ, ГАЗЕТАЛАР ДА ЧЫГАРАСЫ, МӘКТӘП ИШЕГАЛДЫН ТӨРЛЕ СЫННАР БЕЛӘН ДӘ БИЗИСЕ, ЯҢА ЕЛГА ЧЫГЫШЛАР ДА ӘЗЕРЛӘРГӘ КИРӘК. БАР СЫЙНЫФЛАРДА ДА ӘЗЕРЛЕК ЭШЛӘРЕ БАРА.УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ФӘН ОЛИМПИАДАЛАРЫНДА ДА СЫНАТМЫЙЛАР. БУ АТНАДА 7 НЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫСЫ НИЗАМОВ ФӘНЗИЛ РУС ТЕЛЕННӘН ПОБЕДИТЕЛЬ БУЛДЫ.БЕЗ АНЫ ЗУР УҢЫШЫ БЕЛӘН КОТЛЫЙБЫЗ, АЛГА ТАБА ДА ЗУР УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ.ЯНА ЕЛЛАР БЕЛӘН ! |